Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
СОВЕТЫ

КАРАР

2015 елның 2 сентябре № 52/4

Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Советы Уставының 29 статьясы нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Чүпрәле муниципаль районы вәкиллекле органының 2005 елның 3 ноябрендә кабул ителгән 1 номерлы «Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында» гы карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә (2013 елның 9 февралендәге редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Конкурс комиссиясе төзелгәндә конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысы Чүпрәле муниципаль районы Советы тарафыннан, ә икенче яртысы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.»;

2) 6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Конкурс комиссиясе рәисе, аның урынбасары һәм секретаре Чүпрәле муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

*Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль*
*районы Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,*
*Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль*
*районы Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы:* *А.В.* Шадриков